**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЗАРЛЫ МАТАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2020 елның 12 феврале 138№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге 100 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Базарлы Матак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында.**

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге 100 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 7 статьяның 1 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) түбәндәге очраклардан тыш, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәри берлек, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерцияле булмаган (сәяси партия, һөнәри берлек, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты органы белән идарә итүдә катнашу, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиленең рөхсәте белән коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләрнең муниципаль берәмлек Советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешма идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен, я муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар; »;

-Түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә»;

13 статьяның 11 пунктында «җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «күрсәтелгән затларга карата җаваплылыкның башка чараларын куллану» сүзләрен өстәргә;

Кушымтаның 14 статьясындагы 3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ рәвешендә теркәлүне раслый торган документ»;

б) 14 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт килешүе төзегәндә беренче тапкыр эш бирүче тарафыннан хезмәт кенәгәсе рәсмиләштерелә. Беренче тапкыр эшкә кабул ителүче затка индивидуаль шәхси счет ачылмаган булса, эш бирүче тарафыннан Россия Федерациясе Пенсия фондының тиешле территориаль органына күрсәтелгән затны индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәү өчен кирәкле белешмәләр тапшырыла.»;

2) 14 статьяның 3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Россия Федерациясе Пенсия фондының тиешле территориаль органына индивидуаль шәхси счеты ачылмаган беренче тапкыр эшкә кабул ителүче затларны шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәү өчен кирәкле белешмәләр тапшырырга.»;

- 24 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә, моңа 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең муниципаль хезмәте турында» Федераль законда каралган очраклар керми»;

- 24 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.2007 елның 27 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 статьяларында каралган түләтүләр муниципаль хезмәткәрләргә коррупцион хокук бозу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек чорларын, отпускта булуын исәпкә алмаганда, һәм коррупция буенча хокук бозу кылынган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча тикшерү вакыты кертелми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлегенең мәгълүмати стендында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

4. Карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Базарлы Матак авыл җирлеге башлыгы: А. Ф. Никошин